Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең
Кече Шуган поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

27 октябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 27 октябрендә 12 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлеге Кече Шуган поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыененың нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 20 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 18 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 18 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Кече Шуган поселогында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыененың нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлеге Кече Шуган поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кече Шуган поселогы, Кыр урамы, 27 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт

муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Фазлыев